## БЕР ҖЫР ТАРИХЫ

**«Адашкан мәхәббәт»**

(Ринат Гобәйдуллин көе,
Зөләйха Минһаҗева сүзләре)

Айдан төшкән
нурлы күпер
Моңлыларга юл булып.
Шул күпердән,
шул күпердән
Адашкан мәхәббәт бара,
Адашкан мәхәббәт бара
Язмыш буйлап куылып.

Карлы яңгыр үксеп елый
Тәрәзәгә сузылып.
Яңгыр түгел,
яңгыр түгел –
Адашкан мәхәббәт елый,
Адашкан мәхәббәт елый
Тыелып кына, сулыгып.

Гайбәт җыеп
җилләр йөри
Ысылдап, йә сызгырып.
Җилләр түгел,
җилләр түгел,
Адашкан мәхәббәт йөри,
Адашкан мәхәббәт йөри
Бәрелеп лә сугылып.



# «Күл буенда елый-елый язылган җыр ул»

Айзирә Имамова

**Әлеге җыр Татарстанның халык, Россия һәм Башкортстанның атказанган артисты Салават Фәтхетдинов репертуарыннан. Аны беренче булып Чаллы җырчысы Равил Галиев башкарган. Сүзләрен Чаллы шагыйрәсе, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Зөләйха Минһаҗева иҗат иткән. Җырның язылу тарихы бик тә үзенчәлекле. Бу хакта Зөләйха ханым безгә үзе сөйләде.**

**«Анда «комплекс неполноценности» булган»**

«Мине, 16 яшьлек кызны, Баулы районы Яңа Кара Зирек авылына клуб мөдире итеп куйдылар. Үзем тумышым белән Салих авылыннан. Мин килгән көнне бу авылда бер егет армиядән кайтты. Ул мине озатырга теләп йөрде. Тик якын китерергә ашыкмадым. Мин яшәгән фатир хуҗабикәсе дә: «Сиңа күзе төшкән егетләр шактый, берсе белән генә йөрмә», – дип искәртеп торды. Ул әйткәннәрне дә истә тотып, мин берәүне дә якын да җибәрмәдем, еракка да этәрмәдем, һәркайсы белән дә дус булдым. Бу авылда ике ел эшләдем. Теге армиядән кайткан егет миннән гел калмады. Ул бик пөхтә киенә иде. Мин шулчак үзем өчен: «Бу егет минем гомер итәчәк кешем», – дип күңелемә салып куйдым. Тик бу хакта беркемгә дә әйтмәдем. Аның бер кимчелеге бар иде. Мин моны хәзер генә аңладым. Анда русча әйткәндә «комплекс неполноценности» булган. «Син шундый, мин мондый, син минем белән булмассың инде», – дип кабатлый иде. Үзен гел кимсетебрәк карады. Шушы сыйфаты безне аергандыр да...»

● Цитата

**САЛАВАТ ФӘТХЕТДИНОВ:**



«Җырның көй авторы Ринат Гобәйдуллин белән музыкант Илдус Низамов алып килде миңа ул җырны. Тыңлап карадым да, ошаттым. Шулай җырланып китте ул».

● **Цитата**

**РАВИЛ ГАЛИЕВ:**



«Бу җыр минем репертуарга 95нче елда килеп керде. Бик яратып, теләп җырлап йөрдем. Чөнки ул вакытта үзеңнең җырың булу бик дәрәҗәле иде. Күпмедер вакыт җырламый да тордым. Яңа аранжировка ясатып бүгенге көндә ләззәтләнеп башкарам».

### «Туйга чакырып, хат яздылар»

Ике ел эшләгәч, Казанга укырга киттем. Мәдәният институтына кердем. Бу егет районда техникумда укыды. Аның әти-әнисе миңа гел посылкалар салып торды, хатлар алыштык. Безнең йөргәнне бөтен авыл белде. Ул Казанга килештерә иде, мин авылга кайтышлый аларга кунакка кереп йөрдем. Шулай 4 ел чамасы үтте. Институтның соңгы курсында аспирантурага керергә дип, фәнни хезмәт әзерләп Мәскәүгә җибәргәч, «кабул ителдегез» дигән хәбәр килде. Йөргән егетемә бу хакта хат язып салдым. Минем хатны алгач, өч көн эчкән дә бу мотоциклына утырып күрше авылга клубка киткән. Анда дус егете белән бер кызны эләктергән дә, өйләренә алып кайткан. Әти-әнисе аптыраган. Тик кунак кызы кире кайтып китмәгән.

Миңа берзаман егетнең әти-әнисеннән хат килеп төште. «Өйләнә. Туйга кайт» дигәннәр. Мин зур гына картина сатып алдым да, юлга чыктым. Кечке автобуска утырып кайтып барам шулай, күз алдыма мәҗлес табыны килеп басты. Түр башында утырган егетемне һәм кәләшне күз алдына китердем. Мин, 4 ел гашыйк булып йөргән кызы, берүзе кунаклар арасында... Ничек түзәрмен бу хәлгә дидем дә, кыр уртасында автобустан төшеп калдым. Бер күл янына барып, картинаны астыма салып утырдым да еладым. Ә түп-түгәрәк айдан күл буйлап юл сузылган иде. Менә шул юл буйлап айга менеп китәсе килде, миңа анда башка дөньядыр шикелле тоелды. Шулчак күңелдә җырның беренче куплеты туды да: «Айдан төшкән нурлы күпер, моңлыларга юл булып. Шул күпердә адашкан мәхәббәт бара, язмыш буйлап куылып»... Шул сүзләрне төне буе кабатладым да кабатладым. Калган ике куплеты соңрак туды. Җанымнан түгелгәндәй, бер-бер артлы шигырьләр языды. Мин аларны бер блокнотка терки башладым... Аннары иртәнге автобуска утырып, кире Казанга кайтып киттем». Мин ул көнгә, аның шулай өйләнүенә әле дә рәхмәт укыйм. Аның бертуктаусыз янымда: «Син шундый, мин мондый», – дип торуына озак түзәлгән булыр идем микән? Әлбәттә, юк! Ул башкага өйләнмәгән булса мин 44 ел иңгә-иң куеп гомер кичергән Якубымны очратмаган булыр идем. 40 яшемә кичә әзерләп йөргәндә композитор Ринат Гобәйдуллинга «Адашкан мәхәббәт»не укып күрсәттем. Җыр бит инде бу диде ул. Аны кичәмдә Равил Галиев башкарды, аннары Салават Фәтхетдинов сорап алды».